ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2019 г. Заинск № 551

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында" район башкарма комитетының 507нче (02.04.2018) карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210нчы (27.07.2010) Федераль законны гамәлгә ашыру йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Башкарма комитет

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» район башкарма комитетының 507нче карарына, яңа редакциядә кушымта белән, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм муниципаль районның рәсми сайтында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И.Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.М. Рахимова
3-13-37

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.10.2019ел №551
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

**Дәүләт хезмәтләре**

1.Опекага алынган кешеләрне стационар формада хезмәт күрсәтүче психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында карар бирү

2.Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү

3.Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү

4.Балигъ булган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә опекунга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү

5. Опекунга опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү

6. Опекага алынган затларның милке белән сделкалар башкаруга рөхсәт бирү 7.Тору урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекунга опекага алынган затны тору урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү

8. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүенә рөхсәт алу

9. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү

10. Стационар формада социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларындагы эшкә яраксыз гражданнарны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча урнаштыру турында бәяләмә бирү

11.Балигъ булмаган бала исеменнән өстенлекле сатып алу хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү

12.Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге һәм уллыкка алуга кандидат буларак исәпкә кую турында бәяләмә бирү

13.Балигъ булмаган балаларның күчмә милкен алу буенча сделкалар башкаруга алдан рөхсәт бирү

14.Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү

15.Ятим балалар һәм әти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү

16.Балигъ булмаган баланы эмансипацияләү турында карар кабул итү (балигъ булмаган баланы тулысынча эшкә яраклы дип игълан итү)

17.Балигъ булмаган баланыкы булган күчемсез милекне алу буенча сделкалар башкаруга алдан рөхсәт бирү

18.Балигъ булмаган балалар катнашында кредит акчаларын кулланып торак алуга һәм аны залогка (ипотека) бирүгә алдан рөхсәт бирү

19.Балигъ булмаган баланың кертем акчаларын алуга аның законлы вәкиленә рөхсәт бирү

20.Дәүләт милкенә караган архив документларының урнашуы урынына караган сораулар буенча консультация бирү

21.Башкарма комитетның архив бүлеге уку залында танышу өчен дәүләт милкенә караган һәм Башкарма комитетның архив бүлегендә саклана торган архив документларын бирү

22.Дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив фонды буенча архив документлары күчермәләре бирү

23.Туу турында дәүләт теркәве

24.Никах рәсмиләштерү турында дәүләт теркәве

25.Гаилә таркалу турында дәүләт теркәве

26.Уллыкка (кызлыкка) алу турында дәүләт теркәве

27.Әтилекне билгеләү турында дәүләт теркәве

28.Исем алыштыру турында дәүләт теркәве

29.Үлү турында дәүләт теркәве

30.Гражданлык хәлләре актына үзгәрешләр яки өстәмәләр кертү

31.Гражданлык хәле актын дәүләт теркәве турында һәм гражданлык хәле актын дәүләт теркәве фактын раслаучы башка документларны (белешмәләр) кабаттан бирү

32.Гражданлык хәле акты язуын яңарту (юкка чыгару)

## Муниципаль хезмәтләр

1.Шәһәр төзелешен тәэмин итү мәгълүмати системасында булган мәгълүматларны бирү

2.Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләренең схемаларын килештерү 3.Ана (гаилә) капиталы акчаларын кулланып башкарыла торган шәхси торак төзелеше объектларын төзү (төзекләндерү) буенча төп эшләрне башкаруны раслаучы документ бирү

4.Реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм файдалануга рөхсәт бирү

5.Җир эшләре башкару өчен ордер (рөхсәт) бирү

6.Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү

7.Төзүгә рөхсәт бирү

8.Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү

9.Җирлек (шәһәр округы) Генераль планыннан өземтә бирү

10.Төзелү планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларының белдерү кәгазендә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объекты урнаштыруга туры килүе (туры килмәве) параметрларына туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү

11.Төзелгән яки төзекләндерелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында закон таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында белдерү кәгазе җибәрү

12.Капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәгълүмат системасында белдерү урнаштыру һәм бу хакта дәүләт төзелеш күзәтүенең региональ органына мәгълүмат җибәрү

13. Капиталь төзелеш объектын сүтүне планлаштыру турында шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәгълүмат системасында белдерү һәм документлар урнаштыру һәм бу хакта дәүләт төзелеш күзәтүенең региональ органына мәгълүмат җибәрү

14.Муниципаль торак фонды торак бинасын социаль найм килешүе буенча гражданга тапшыр

15.Чернобыл АЭСы фаҗигасе, “Маяк” җитештерү берләшмәсендә авария нәтиҗәсендә радиация нурланышына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификаты бирү

16.Күченеп кайтырга мәҗбүр булганнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында һәм торак сатып алуга субсидия бүлеп бирүгә Дәүләт торак сертифика алуга исәпкә кую

17.Социаль найм килешүе белән бирелгән торак биналарны алмаштыруга ризалыкны алу

18. Социаль найм килешүе буенча гражданинга муниципаль милект булган торак бинасы бирү

19. Торакка  мохтаҗ аерым категория гражданнарны исәпкә кую

20.

21.Татарстан Республикасы социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую

22. Торак бинаны (торак булмаган бинаны) торак булмаган бинага (торак бинага) күчерү турында (күчерүдән баш тарту) белдерү бирү

23.Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү

24.Җирле әһәмияткә ия юллардан файдалаучы машина йөртүчеләргә юллар торышы турында мәгълүмат бирү

25.Муниципаль район территориясе өстендә авиация эшләре, парашюттан сикерүләр, һава судноларының күрсәтмә очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, аэростатлар күтәрү башкаруга рөхсәт бирү

26.Тулысынча яки өлешчә муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буенча узучы юллар аркылы үтүче авыр йөк, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү

27.Агачларны, куакларны кисүгә, аларның очларын кисүгә яки утыртуга рөхсәт бирү

28.Бинаны торак бина дип, торак бинаны тору өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны аварияле һәм җимерергә яки төзекләндерелергә тиеш дип, бакча йортын торак йорт дип, торак йортны бакча йорты дип тану

29.«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү

30.Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү

31.Архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү

32. Муниципаль архивның уку залында куллану өчен архив документларын бирү

33.Юридик затларга архив эше һәм делопроизводствода документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү

34.Архив документлары урнашу урынына караган сораулар буенча консультацияләр бирү

35.Муниципаль архивка саклауга таркалган оешмаларның личный составы буенча документларны кабул итү

36.Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү

37.Күчемсез милек оъектына адрес бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару

38. Торак бинаны гражданин милке итеп тапшырганда документлар төзү

39. Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар кабул итү

40.Нотариаль эшчәнлек башкару

41.Белешмә (өземтә) бирү

42.Муниципаль берәмлекнең муниципаль милкен торг үткәрмичә генә бушлай файдалануга тапшыру

43.Муниципаль милекне оператив идарә итү хокукында муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә һәм хуҗалык алып бару хокукында муниципаль унитар предприятиеләргә рәсмиләштерү (беркетү)

44.Муниципаль милек реестрыннан өземтәләр бирү

45.Муниципаль милектә булган һәм арендага тапшыру өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү

46. Муниципаль казнаны тәшкил итүче милекне арендага бирү

47. Муниципаль милекне арендалау, оператив идарә итү, бушлай файдалану, хуҗалык итү килешүенә үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешү төзү

48.Муниципаль милек реестрына кергән муниципаль милекне арендага бирү

49.Мондый килешү төзү хокукына торг нәтиҗәләре буенча муниципаль милек белән бушлай файдалану килешүе төзү

50.Җир кишәрлеге урнашу яки территориянең кадастр планында җир кишәрлекләре схемасын раслау

51.Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү

52.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) куллануга тапшыру

53.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бушлай милеккә тапшыру

54.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бушлай куллануга тапшыру

55.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торг үткәрмичә сату

56.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торг үткәрмичә арендага бирү

57.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма милекчеләренә милеккә яки арендага бирү

58.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион формасында уздырылучы торгларда арендага бирү

59.Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелүче торгларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә бирү

60.Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү 61.Муниципаль милектә булган җирләрне һәм җир кишәрлекләрен куллануга рөхсәт бирү

62. Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен крестьян (фермер) хуҗалыклары эшчәнлеге башкару өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына милеккә (арендага) бирү

63. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү

64. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бакча эшчәнлеге алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү

65. Шәхси яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бер категориядән (авыл хуҗалыгы җирләреннән кала) икенче категориягә күчерү турында карар кабул итү

66. Җир кишәрлеге белән даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукын яки җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату турында карар кабул итү

67. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү

68. Җир кишәрлеген арендалау килешүенә үзгәрешләр кертү

69.Муниципаль преференциялүр бирү

70. Җир кишәрлекләрен милеккә бушлай алырга хокуклы затлар буларак исәпкә кую

71. Муниципаль милектә булган җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү

72. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү

73.Гамәлдәге муниципаль милекне арендалау килешүен өзү

74. Гамәлдәге җир кишәрлеген арендалау килешүен өзү

75.Җир кишәрлеген арендалау килешүе буенча арендаторның хокукларын һәм бурычларын өченче затка күчерүне килештерү

76. Муниципаль милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына милеккә ия булуга һәм (яки) куллануга тапшыру

77.Аерым максатларда ачык сервитут билгеләү

78.Законсыз саклanучы яки табылган корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлату җайланмалары һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле тәстә тапшырган өчен акчалата бүләкләү турында карар кабул итү

Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү

Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында белдерү кәгазе бирү

Рөхсәт ителгән төзелеш, ныклап төзекләндерү объектларын төзекләндерүнең соңгы чикләреннән тайпылуга рөхсәт бирү

Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген аныклау

Муниципаль торак фонды торак биналарын гражданнар милкенә күчерү вакытында документлар рәсмиләштерү

Гамәлдәге муниципаль милекне арендалау килешүен өзү

Муниципаль милектә булган сай су объектын яки аның өлешен куллануга тапшыру турында рөхсәт бирү

Муниципаль торак фондындагы торак биналарны хезмәт торак бинасы найм килешүе буенча гражданнарга тапшыру

Социаль найм килешүе буенча бирелгән муниципаль торак фонды торак биналарын алыштыру буенча документлар рәсмиләштерү

Авыл җирлегендә яшәгән гражданнарга, шул исәптән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр бирү